وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№7 (124). 17 февраль 2012 / 25-раббигыль-әүвәл-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Мөселман киносы фестивале. Киләчәге ничек булыр? 2



"Изге Вәли" көне, и гади Фәрикамал дәгъвасы 3



Коръән савытлары 4

## ЯҢАЛЫКЛАР

### БӨГЕЛМӘ ИМАМНАРЫ – КВАЛИФИКАЦИЯ ҮСТЕРҮ КУРСЛАРЫНДА

15 февральдә Бөгелмә районы имам-хатыйблары өчен квалификация үстерү курслары тәмамланды.

Ике атна дәвамында Бөгелмә районыннан 11 имам дини белемнәрен арттырды, социаль әһәмиятле дөньяви фәннәр буенча да мәгълүмат алды. Укулар тәмамлангач, аларга ТР мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре аттестация үткәрде. Барлык имамнар да, зачётларын уңышлы тапшырып, курсларны тәмамлау турында таныклыклар алды.

### БАЛЫК БИСТӘСЕНДӘ КОРЪӘН УКУ БӘЙГЕСЕНӘ ӘЗЕРЛӘНӘЛӘР

Балык бистәсе районы имам-мөхтәсибе Сәүдәхан хәзрәт Гайнетдинов хәбәр иткәнчә, мөхтәсибәттә март аенда Җәмигъ мәчеттә узачак Коръән уку бәйгесенә әзерлек бара. Әлеге чарада IX сыйныфка кадәрге яшүсмерләр катнаша алачак.

"Районыбыз авылларындагы мәчетләр каршында дини дәресләр алып баручы уникеләп мөгаллим бар, әлеге Коръән бәйгесенә һәрберсе ике катнашучы алып килә ала. Бүгенге көндә авылларда ярышның беренче этабы бара. Бәйгенең йомгаклау этабына администрация вәкилләре дә, шулай ук Диния нәзарәтеннән дә кунаклар көтелә", - дип билгеләп үтте имам-мөхтәсиб.

### ТУГАН КӨННӘР

14 февраль көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәте хезмәткәрләре "Апрель" реабилитация үзәгенә барып, сабыйларның туган көннәренә багышланган бәйрәм чарасы үткәреп кайтты. "Апрель"дә - "Туган көн" дип аталган әлеге чараны үткәрү матур традициягә әйләнеп бара.

Диния нәзарәтенең ярдәм күрсәтү һәм хәйрия бүлеге җитәкчесе Гөлнара Садыйкова: "Мондый чараларны үткәрү үзебез өчен дә зур вакыйга. Балаларның йөзләрендә шатлык күрү - икеләтә бәхет", - дип билгеләп үтте һәм туган көннәре кышкы айларга туры килгән балаларга истәлекле бүләкләр тапшырды.

### ЯҢА САЙТ АЧЫЛДЫ

Интернет челтәрендә "Татарстанның ислам мәгарифе" дип аталган яңа сайт эшли башлады. Сайт ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең мәгариф һәм фән бүлеге эшчәнлеген яктыртачак.

Биредә уку программалары урнаштырылган, шулай ук Татарстандагы мөселман уку йортлары турында шактый күп мәгълүмат бирелгән. Тиздән әлеге сайтта республикабызның ислам мәгарифе яңалыклары куелып барылачак. Сайтның адресы: www.magaryf.ru.

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

# Ислам - урталык дине

**"Идеология" сүзе грек теленнән кергән. Бу система төрле социаль сыйныф, төркем, җәмгыятьнең мәнфәгатьләрен белдерүче концептуаль булган караш һәм идея; биредә кешеләрнең чынбарлыкка һәм бер-берсенә булган мөнәсәбәтләре чагылыш таба һәм бәяләнә, шулай ук җәмгыятьтә хакимлек итүче власть һәм идарә итү формаларына (консерватив идеологияләр) яки аларның барлыкка килүләренә нигезләнәләр (радикаль, революцион идеологияләр).**

Безгә дөньядагы бик күп идеологияләр билгеле. Алар сәяси дә, дини дә булырга мөмкин. Исламга килгәндә, бу идеология галәм, кеше һәм яшәештәге бар нәрсәне Тудыручы - Аллаһы Тәгалә торуын раслый. Шуңа күрә, ислам дине нигезенә Аллаһның барлыгына ышану ята. Мөселманнар өчен дин һәм шәригать - ул Аллаһ тарафыннан билгеләнгән закон һәм кодекслар җыелмасы, аны кулланып, кеше бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхеткә ирешә. Ислам - ул билгеле бер яшәү рәвеше.

Аларның чыганагы - хакыйкатьне ачу дип раслаучы идеологияләр берничә сынау үтәргә тиеш була, аның беренчесе һәм иң мөһиме - эзлеклелек. Эчке эзлеклелек китаптагы бер раслау шушы ук китаптагы икенче раслауга каршы килмәскә тиеш булуын белдерә. Гомумбилгеле фактларның психология, физика, химия, тарих, география, биология һ.б. өлкәләрдән булуларына карамастан, китаптагы фактларга каршы килмәскә тиеш. Бу тышкы эзлеклелек була.

Бүгенге көндә төрле секталар һәм диннәрнең саны шулкадәр күп ки, аларның төп билгеләрен һәм хакыйкатькә туры килүләрен аңлавы кыен. Чамасызлык һәм җитешсезлек һәрвакыт гаеп саналган: зирәк кешеләр дөнья эшләрен артык куучыларны, табиблар даруларны артык яки бик аз куллануны, спорт тренерлары күнекмәләрне аз яки бик күп башкаруны, диетологлар витаминнарны чамадан тыш күп яки кирәгеннән аз куллануны начар дип исәплиләр. Ислам дине урталык ("васатыя" - гарәпчә "урталык") дине булуы турында хәбәр иткән күп кенә хәдисләр бар.

Урталык - пәйгамбәрләребез юлы. Урталык югалган очракта түземсезлек һәм фанатизм барлыкка килә. Аллаһы Тәгалә урталыкны - "васатыяне" - рухи һәм җәмгыять тормышында мөселманнар өчен кулланма итеп биргән, шуңа күрә динебез һәр вакыт, һәр урын, һәр ил һәм һәр кеше өчен ачык. Васатыя - кешеләрнең аермаларына һәм ихтыяҗларына карамастан, бер-берсе белән дус яшәргә булыша торган ислам диненең урталык юлы.

Нәтиҗәләр ясау һәм тышкы дөнья белән дөрес мөнәсәбәтләр урнаштыру өммәтебез өчен бүгенге көндә бик тә мөһим.

Чөнки нәкъ менә бүген мөселман өммәте җәмгыятьтә лаеклы урынын алырга, йогынтысын көчәйтергә һәм уңышларга ирешергә тиеш. Урталык юлын сайлау - ислам диненең асылына төшенү ул.

Васатыя берничә мәгънәне белдерә: яхшылык, урталык, түземлелек, толерантлык, башкаларга дустанә мөнәсәбәттә булу, башка кешенең фикерен хөрмәт итү, шәфкатьлелек.

Васатыя - кешене чамасызлыктан һәм дини йолаларны үтәүдә, дин хокукы сорауларына җавап биргәндә, шәригатьне үтәгәндә, фәтвалар чыгарганда гамьсезлектән, ваемсызлыктан саклаучы юл.

*Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

# ВАТАН КАЙДАН БАШЛАНА?



**Болгар-татар халкының бай дәүләтчелек тарихы бар. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, әле VI гасыр уртасында - 552 елда ук - болгар-татар дәүләтчелегенең дә башлангычы булган Төрки каһанлыгы оеша. Аннары төзелгән Кимәк һәм Хәзәр каһанлыклары, Бөек Болгар, Идел Болгары, Дәште Кыпчак, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Россия империясе, СССР, Россия Федерациясе - боларның барысын да бабаларыбыз я үзләре төзегән, я башка халыклар белән бергә төзешкән, ул дәүләтләрне үстерүдә, чит ил басып алучыларыннан саклап калуда үзеннән өлеш керткән.**

Бәхеткәме, әллә язмыш каргагангамы, татарлар - гомер-гомергә күп ватанлы халык. Алар Идел буенда һәм Уралда, Себердә һәм Кырымда, башка бик күп кыйтгаларда үз җирләрендә, үз ватаннарында яшиләр. Моннан күп гасырлар элек Польша, Балтик буе илләрен дошманнардан саклап калу өчен ул төбәкләргә киткән татарларның бер өлеше шунда төпләнеп калган, ул җирләрне үз ватаны иткән. 1917 елгы Октябрь инкыйлабына (революциясенә) кадәр һәм аннан соң - Төркиягә, Финляндиягә, башка мәмләкәтләргә; Идел буендагы корылык һәм ачлык елларында - Урта Азиягә; илне индустрияләштерү чорында Донбасс шахталарына киткән алар. Хәзер алар, аларның балалары һәм оныклары шул илләрнең тулы хокуклы гражданнары, ул дәүләтләр исә - аларның ватаны.



Хәер, бу бер безнең халыкка гына хас күренеш түгел. Кешелек дөньяга барлыкка килгәннән үк төрле ырулар, кабиләләр, халыклар, даими рәвештә күченеп, урын алыштырып торганнар, бер-берсенең җирен яулап алганнар, яңа дәүләтләр төзегәннәр. Хәзер дөньяның иң куәтле иле булган Америка Кушма Штатларын да йөзләрчә милләт вәкилләре төзегән. Америка материгы ачылгач, анда дөньяның барлык кыйтгаларыннан халык агылган. Алар, андагы төп халыкны кысрыклап, аларның борынгы культурасын җимереп, "Яңа дөнья" төзегәннәр. Аннары Африканың төрле илләреннән бирегә коллар китерелгән. Бүген аларның барысының да ватаны - АКШ. Бу - Канада гражданнары булган инглизләргә һәм французларга да, кайчандыр Көньяк Америка илләренә күченгән испаннарга һәм португалларга да, башка бик күп халыкларга да хас күренеш.

Моннан чирек гасыр еллар элек без СССР гражданнары идек. Ил таралып, элеккеге союздаш республикалар урынына яңа дәүләтләр барлыкка килгәч, татарлар тагын да бүлгәләнде. Хәзер безнең Россиядән читтә яшәүче милләттәшләребез - Казакъстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Украина һ.б. илләр гражданнары. Ул илләр - аларның ватаны.

Күрәбез, бер генә халык та, бер генә милләт тә, үз кабыгына бикләнеп, бер төбәктә генә йомылып яши алмый. Хәзерге глобальләшү шартларында илләр, халыклар арасында чикләр тагын да шартлырак була бара. Димәк, кешенең, халыкларның ватаннары да үзгәрә. Әмма, "ватан китсә дә", милләт кала, халык кала, кавем кала. Нәкъ шагыйрь әйткәнчә:

Ни газизрәк - бу ватанмы?
Аһ, туган каүмем газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!
Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр!

Бүген Татарстанда йөздән артык милләт вәкиле яши. Һәм алар - татарлар кебек үк - Россия гражданнары, безнең уртак ватаныбыз - Россия. Бүгенге вәзгыять шундый.

Киләчәк ничек кенә булмасын, бүгенге көндә без - Россия гражданнары. Рус өчен дә, татар өчен дә, бу илдә яшәүче йөзләрчә башка милләт кешеләре өчен дә ул - уртак ватан. Бу - тарихи чынбарлык.

Сүз уңаеннан, гражданин сүзе (латинчадан) крепостьта, полиста яшәүче дигәнне аңлата. Борынгы заманнарда шәһәр крепосте эчендә яшәүчеләрне - гражданнар дип, крепостьтан, шәһәрдән читтә яшәүчеләрне варварлар (спайдерлар) дип атаганнар. Гражданнар шул полистагы тәртипләрне, кагыйдәләрне, җәмгыять билгеләгән вазифаларны үтәгәннәр. Цивилизация төшенчәсе дә шуннан килеп чыккан. Ә варварлар исә шәһәр (полис) тәртипләренә буйсынмаганнар, аның кагыйдәләрен үтәмәгәннәр.

Без - варварлар түгел, Россиянең тулы хокуклы гражданнары. Шул ватанның гражданнары буларак, без аның законнарын үтәргә, аны сакларга һәм якларга бурычлы.

Шул ук вакытта безнең кече ватаныбыз да бар. Ул - Татарстан Республикасы. Казан ханлыгы, җимерелеп, Россия империясе составына кертелгәч, безнең төбәк озак еллар дәвамында бернинди дәүләтчелек билгеләре булмаган Казан губернасы сыйфатында яши. Әмма татар халкы беркайчан да үзенең дәүләтчелеген торгызу омтылышыннан баш тартмый.

*(Ахыры 3 нче биттә.)*

# МӨСЕЛМАН КИНОСЫ ФЕСТИВАЛЕ. КИЛӘЧӘГЕ НИЧЕК БУЛЫР?

***Узган атнада танылган "БИЗНЕС Online" интернет-басмасы укучылары белән үткәрелгән интернет-конференция барышында Татарстанның мәдәният министры Айрат Сибагатуллин Казанда үткәрелә торган "Алтын мөнбәр" мөселман киносы фестивале турында сенсацион белдерү ясады. Исегезгә төшерәбез: үткән елда фестивальдә призлы урыннарның берсен үзенең ислам диненә каршы карашлары белән билгеле булган Сибель Кекилли исемле порно-актриса яулаган иде.***






Шуңа бәйле рәвештә күпләрне "Алтын мөнбәр" фестиваленең киләчәге борчый.

Фестивальнең дәвамы булачакмы (яки яңарыш кичерәчәкме?), әллә ул үзенең мөселман юнәлешен югалтачакмы? Бу сорауга җавап итеп, мәдәният министры болай диде: "Мөселман киносы сәнгатен генә түгел, гомумән, кино сәнгатен аңлаучы абруйлы кешеләрне чакырырбыз. Бу фестивальгә ниндидер төсмер бирү кирәк микән? Аның концепциясен яңадан уйларга була, ләкин мин моңа бүгенге көндә әзер түгел. Яхшы эш эшләнелгән, шуңа күрә миңа кадәр эшләнгәнне тиз генә үзгәртәсе килми".

Игътибарлы укучы Айрат әфәнде сүзләрендә гаҗәпкә калдыра торган ике төп фикерне күрә ала. Беренчесе - ыгы-зыгыны китереп чыгара торган буталчык, мәсхәрәле вакыйгаларны булдырмас өчен министр "абруйлы кешеләрне" чакырачак. Икенче фикер - министр "Алтын мөнбәр" фестиваленең мөселман юнәлешен юкка чыгарырга әзер, ләкин ашыгыч рәвештә түгел.

Бүтән сүзләр белән әйткәндә, Айрат әфәнде башта фестиваль кунаклары һәм катнашучылары исемлегенә мөселманнарның порнога каршы булучыларының керү мөмкинлеген булдырмаска тырышачак. Аннан соң инде фестивальнең мөселман юнәлешен юкка чыгарып, аны бары тик Казан фестивале буларак кына үткәрәчәк. Уйлап кына карагыз! Нәрсә килеп чыга соң? Югары дәрәҗәдә утыручы түрә мөселман киносы фестивален порно-йолдызларыннан башка күз алдына да китерә алмый түгелме? Сибель Кекилли кебек ислам диненә каршы актрисалар Казан фестивалендә булмый икән, аны мөселман дип атарга да кирәкмиме? Ниндидер саташу бит бу!

Моңа ышанасы да килми. Татарстанның яңа мәдәният министры республикабыз тарихына кинофестивальне саклап калучы һәм аны чын мөселман киносы фестивале итеп үткәрүче буларак кереп калыр, дип ышанасы килә. Ләкин моңа ышаныч бик аз, чөнки кинофестивальгә ислам диненә каршы булучы порно-йолдызларны чакырып, Татарстанны хур иткән кешеләрнең эшендә министр гаеп тапмый, ә киресенчә: "Яхшы эшләгәннәр", - ди...

***Рөстәм хәзрәт БАТЫР,***
***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы рәисе***



## Иран – Россия игътибарыннан читтә түгел

**Берничә ил тарафыннан Иранга атыш җәйгә таба ясалырга мөмкин, дип белдерде РФ Генераль штабы башлыгы Николай Макаров 14 февраль көнне Мәскәүдә узган матбугат очрашуында.**

Россия армиясенең кораллануы мәсьәләләреннән тыш, журналистлар белән очрашуда хәрбиләр катнашын потенциаль яки теоретик яктан таләп итәргә мөмкин булган эчке сәясәткә кагылышлы актуаль сораулар күтәрелде.

"Иран алар өчен авырткан җир. Безнең өчен әлеге көньяк юнәлеш принципиаль әһәмияткә ия", - дип ачыклык кертте Н.Макаров.

Генерал ассызыклаганча, "Генштаб Төньяк Африка һәм Якын Көнчыгыш илләрендәге торышны игътибар белән күзәтү өчен барлык кирәк булган чараларга да ия". Ул шулай ук: "Тунис, Мисыр һәм Ливиядәге вакыйгалардан башлап, Генштаб әлеге илләр тирәсендәге ситуацияне күзәтеп килде, - дип тә өстәде. - Бездә шул ук Ливиядә махсус бүлекчәләр ничек хәрәкәт иткәнлеге, оппозициянең ничек әзерләнгәнлеге теркәлгән күптомлы мәгълүматлар бар".

# ГАБДУЛЛА хәзрәт РӘХМӘТУЛЛИН (XIX гасыр урталары – 1923)

**Рәхмәтуллин Габдулла Гобәйдулла улы - танылган дин әһеле һәм педагог. Ул Сембер губерниясе (хәзер Татарстанның Буа районы) Буа өязе Карлы авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә.**

Башлангыч дини белемне үзенең әтисе Гобәйдулла хәзрәт Рәхмәтуллин мәктәбендә алганнан соң, укуын 1887 елда Казандагы беренче Җәмигъ мәчете мәдрәсәсендә - Шиһабетдин Мәрҗанидә дәвам иттерә. Мәрҗани вафат булганнан соң, Казанның "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә укырга керә. Аны тәмамлагач, Буага кайта һәм 1905 елның октябрендә шәһәрдә яңа төзелгән икенче мәхәллә мәчетенә имам булып сайлана. Шунда вафат булганчы хезмәт итә.

1907 елда Габдулла хәзрәт мәчет каршында Буа шәһәренең икенче мәдрәсәсен - "Гыйльмия" исемле мәдрәсә ача. Бу мәдрәсә җәдиди укуга нигезләнгән була. Мәдрәсәнең уку-укыту тәртибе һәм күпкырлы гыйлем бирүләрнең һәммәсе дә шәһәрдә һәм әйләнә-тирәдә аның тиз арада абруе үсүгә китерә. Елдан-ел анда белем алырга теләүчеләрнең саны артканнан арта бара. Мисал өчен, 1913 нче елларда биредә йөз иллеләп шәкерт укый һәм аларга җиде мөгаллим белем бирә. Совет хөкүмәте урнашкач, "Гыйльмия" мәдрәсәсе 1919 елда I дәрәҗәдәге икенче Буа совет мөселман мәктәбе итеп үзгәртелә. Мәктәп белән Г.Рәхмәтуллин гомеренең соңгы көннәренә кадәр җитәкчелек итә.

Габдулла хәзрәт 1923 елның 13 октябрендә бакыйлыкка күчә. Ул Буа шәһәренен татар зиратына җирләнә. Габдулла Рәхмәтуллин берсүзсез үз заманының абруйлы шәхесләренең берсе була. Ул ислам дине үсешенә һәм Буа өязендәге мөселманнарның аң-белеме артуына зур өлеш кертеп, күп шәкертләр тәрбияләп калдыра.



Фотода: Габдулла хәзрәт эшләгән мәчет. Бүгенге көндә ул Буа шәһәренең Габделмәлик исемендәге Үзәк Җәмигъ мәчете исемен йөртә. (Автор фотосы.)

***Рәшид МАЛИКОВ,***
***ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты аспиранты***

# Без өммәткә Коръән хакыйкатьләрен җиткерүчеләр

**Ислам диненең нигезендә Аллаһы Тәгаләнең сүзе - Коръәни-Кәрим ятуын бөтенебез белә. Коръәндә бәян ителгән илаһи тәгълимәт вә кыйммәтләр халкыбызның рухи мәдәниятенең нигезендә, татарның фикерләү культурасының уртасында ята дип әйтә алабыз.**

Халкыбыз ислам динен кабул итү белән үк, Коръән белән таныша, аны үз итә башлый. Коръән белән андый якыннан танышу әле сәхабәләр заманында ук булган икәнлеген күп чыганаклар раслый.

Табигый, башта Коръән халкыбызда кулъязма формасында тарала. Бездә тулаем кулъязма китабы культурасы барлыкка килә. Кулъязма китапның кыйммәтлегенә һәм җитештерүнең катлаулыгына карамастан, Казанда хәзерге вакытта да шундый 50 мең китап саклануы халкыбызның китапка булган мәхәббәтен күрсәтә.

Басма китапка килгәндә исә гарәп хәрефләрендә беренче китаплар Европа илләрендә булдырыла. Шәрык илләрендә китап бастыру эшенә шикләнеп караганнар.

Шуның өчен өммәт күләмендә нәкъ менә татарлар тарафыннан беренче басма Коръән нәшер ителүе очраклы түгел, чөнки без менталитет, тәрбия буенча мөселманнар булып, шул ук вакытта техника-технология яңалыкларына да ачык халык. Тарих күрсәтә ки, бабаларыбыз типография эшенә ия булу өчен гел тырышлык куйган. Алар тырышлыгы белән дөньяда беренче тапкыр басма Коръән безнең илдә нәшер ителә дә инде. Бу вакыйга 1787 елда Санкт-Петербургта тормышка ашырыла. Әби патша Екатерина II әмере белән Россия мөселманнарының күпсанлы сорауларына карата шушы изге Китап җыелма хәрефләр белән бастырыла. Хәрефләр рәсемнәрен мулла Госман Исмәгыйль хәзрәт сурәтләп әзерләп бирә. Димәк, ошбу китап баштан ук мөселманнар эше. XVIII гасырда ул Коръән тагын 1789, 1790, 1793, 1796 һәм 1798 нче елларда яңа тиражлар белән нәшер ителә.

1799 елда Павел I Казанда типография ачарга рөхсәт бирә.

Казан гимназиясенә Петербург хәрефләре күчерелә һәм 1801 елда инде Казанда янәдән Коръән дөнья күрә.

1803 елдан башлап Казанда зур меңләгән тиражлар белән Коръән бастырыла башлый, ул чит илләргә дә сатыла.

"Казан басмасы" исемле феномен калыплана. Шушы безнең Коръән бөтен басма Коръәннәр өчен үрнәк булып китә. Төркиядә, Мисырда, Һиндстанда соңыннан Коръәнне бастыру эшенә алынганда безнең калыпка иярәләр.

Саннарга килгәндә, 1802-1859 елларда Казанда Коръән 150 мең экземплярда басыла.

А.Б.Халидов мәгълүматларына караганда, 1917 елга кадәр бездә 172 тапкыр Коръән басыла, ә Һәфтияк - 191 тапкыр.

Күрәбез ки, татарлар Коръәнне халыкларга җиткерү эшендә үзенә күрә революция ясый. Чөнки кулдан язу Коръән нөсхәләрен бик кыйммәт һәм сирәк әйбер итә иде.

Басма Коръәнне булдыру исә Изге китапны киң укучы массаларына җиткерү дигән сүз. Без шушы бабаларыбызның гамәле белән горурланырга тиешбез, чөнки өммәткә Коръән хакыйкатьләрен җиткерү, күп халыкларга Коръәнне кулланырлык итү - зур тарихи казаныш, мәдәниятне, мәгарифне үстерү. Бер сүз белән әйткәндә, цивилизацион ургылу (прорыв) булып тора.

***Вәлиулла ЯКУПОВ,***
***тарих фәннәре кандидаты***

# "Изге Вәли" көне, яки гади Фәһрикамал дәгъвасы

*(Дәвамы. Башы "Дин вә мәгыйшәт" газетасының 10 февраль санында.)*

Иртә белән өчәүләп чәй эчеп утырганда, Фәһрикамал апа һава торышын тыңлыйм дип, радио тавышын көчәйтеп җибәрде. Шул мәлдә күңелгә хуш, йомшак кына хатын-кыз тавышы саф татарча болай сөйли иде: "Хөрмәтле радиотыңлаучылар! Бүген яшьләр көтеп алган шатлыклы вакыйга - Изге Вәли көне. Гашыйклар көне уңаеннан сезне ихластан котлыйбыз!"

Шушы игълан яңгыраганнан соң, әби кулындагы чынаяк ирексездән тәлинкәсенә шап итеп килеп төште. Илгизәр исә, шатлыгын яшерә алмыйча, сикереп торды да, әсәрләнеп лакылдарга тотынды:

- Ә! Менә-менә-менә!!! Әйттем бит мин сезгә "Валентин көне" дип! Татарчасы "Изге Вәли көне" була инде ул. Әни, син ул Вәлине белергә тиеш, сезгә мәдрәсәдә аның турында сөйләгәннәрдер!

Болай да хафага төшкән Гөлиянең шушы сүзләргә каршы каты итеп кычкырасы, хәтта аңа сугып җибәрәсе килде, ләкин бар сабырлыгын җыеп, Илгизәргә ул болай дип җавап бирде:

- Безнең динебездә, улым, "фәлән изгенең көне" дип билгеләп үтелә торган көннәр юк. Ә кемгәдер гашыйк булуыңны бөтен дөньяга белдерү, җәмәгатьчелек белән моны бәйрәм итү - әхлаксызлык кына түгел, зур ахмаклык та ул, минемчә.

- Ә минемчә, монда бернинди начарлык юк, дип карышты Илгизәр. - Кешеләрнең бер-берсенә "яратам" диюдән нинди зарар булсын ди инде?

- Их, улым, син бу яшеңдә барысын да аңлап бетермисеңдер шул, - дип сүзгә кушылды Фәһрикамал апа. - Илгә, туган якка, әти-әнигә карата булган мәхәббәт бер нәрсә, ә ир белән хатын мәхәббәте - ул бөтенләй башка нәрсә. Ул һәркемнең шәхси, бары бер кешегә генә ачыла торган серле хисе. Андый мәхәббәт, кем әйтмешли, тыйнак һәм оялчан булырга тиеш.

- Шулай шул менә! - диде Гөлия ныклы һәм ышанычлы тавыш белән. - Инде болай да руслашып беттек, ул гына түгел - мәктәпләргә чит ил бәйрәмнәре, тузга язмаган "Валентин көннәре" кертә башладылар. Әле кара син аларны - "Изге Вәли" дип татарчалатып "җиффәрәләр". Бу бит үз динебезне үзебез мыскыл итү! Бармы соң ислам тарихында ир-хатын мәхәббәтенә дан җырлаучы Вәли исемле изге? Юк. Ә нәрсә дип тагалар аны безгә радиодан? Мәктәпләргә ник кертәләр? Ярар, монда кухняда зарланып кына мәсьәләне ачыклап булмас. Эштән кайтышлый мәктәпкә кереп, укытучыларыгыз белән сөйләшәм әле, ни диярләр тагын....



* * *

Көндез, сәгать өч тулып киткәннән соң, Гөлия улы укый торган мәктәп янында басып тора иде. Эчендә ярсуы һәм дәгъвалары ташып торса да, йомшак һәм оялчан табигатьле булганга, ул бераз вакыт керимме-юкмы дип ишек төбендә тартынып-икеләнеп торды. Нәрсәдер сизгәндәй, мәктәпкә керәсе килмәде аның. Ләкин берадан, өйдәге сөйләшү хәтерендә яңаргач, аяклары үзеннән-үзе мәктәпкә алып керде.

Беренче каттагы зур залдан музыка, балалар тавышы ишетелә иде. Бәлкем, аның Илгизәре дә шул залдадыр? Ул җырларга тиешле җырның исеме искә төшкәч, Гөлия, кабаланып, директор кабинетына юнәлде.

Сәркатиб бүлмәсендә утырган кыз таныш булып чыкты. "Күрше Рәмзиянең килендәше Ләйсән бит бу!" - дип шатланып уйлап куйды Гөлия. Ләйсән дә, аны танып, елмаеп каршы алды:

- Кер әйдә, кер, Гөлия, утыр. Нинди җилләр китерде үзеңне?

- Бүген мәктәбегездә ниндидер "Валентин көне" дип концерт куялар икән, мин анда улымның катнашуына каршы. Шул хакта директор белән сөйләшеп булмасмы икән дип килгән идем.

- Кызганыч, директор бүген булмый. Улың ничәнче сыйныфта укый соң? VIIa? Аның сыйныф җитәкчесе хәзер дәрестә, ун минуттан, дәрес беткәннән соң, аны күреп сөйләшә аласың, ләкин... ләкин катлаулырак кеше шул ул, үзең дә беләсеңдер.

- Кимчелек һәркемдә дә бардыр инде. Мин шуны гына аңламыйм: ни өчен балаларга өчәр-дүртәр "валентинка" дигән мәхәббәт открыткалары язарга кушкан ул? VII сыйныф өчен генә түгел, унберенчеләр өчен дә бу сәер бит!

- Их, Гөлия, әйтсәм әйтим инде: ул Казаннан шушы открыткаларны очсызга гына күпләп алып кайткан да, бәясен арттырып, укучыларга саткан. Ләкин бел: мин сиңа бернәрсә дә әйтмәдем, югыйсә тагын кара тавыш чыгачак. Болай да ишетмәгәннәрем калмады...

Укытучының катырак холыклы булуын яхшы белгәнгә күрә, дәрес бетүен белдерткән кыңгырау тавышы Гөлия өчен сугыш турындагы киноларда ишеткән "тревога" сиренасы кебек тоелды. Бәлки, алай гына да түгел, олы бәрелеш алдындагы хафалы набат иде ул... Әмма улының әхлакый сафлыгын, үзенең дөньяга карашын яклау теләге усал укытучы образындагы дәһшәтле көчкә каршы чыгарга рухландырып, Гөлиягә тыныч сәркатиб бүлмәсеннән хәвефхәтәр каршысына чыгып китәргә ярдәм итте. Хәер, ул мөгаллимә белән низаглашырга җыенмый иде. Ул аңа фәкать үз фикерен белдерәчәк, Илгизәрнең бүгенге "изге" чарада катнашмаячагын әйтәчәк. Ә калганын үзе белсен...

**(Ахыры киләсе санда.)**

**Ришат КУРАМШИН,**
**Кукмара мәдрәсәсе директоры**

# ВАТАН КАЙДАН БАШЛАНА?

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

СССР төзелгәч, Татарстанның да, Үзбәкстан, Казакъстан, Балтик буе республикалары кебек үк, союздаш республика статусы алу мөмкинлеге була. Милләтпәрвәрләребез шуңа ирешү өчен күп көч куя. Татарстанга автономияле республика статусы бирелә.

Шулай да, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү уңай күренеш була. Чөнки Россиянең башка төбәкләреннән берни белән дә аерылмаган губернадан үз Конституциясе, башкаласы, кайбер дәүләтчелек атрибутлары булган республика итеп үзгәртелүе халыкның канына сеңгән дәүләтчелек хәтерен яңадан тергезеп җибәрүгә импульс бирә. Әнә шуңа күрә дә СССР таралып, барлык союздаш һәм автономияле республикалар мөстәкыйльлек өчен көрәшкә күтәрелгәч, татар халкы, Татарстан бу көрәшнең алгы сафына басты. Ул үзенең яңа Конституциясен кабул итте, үзенең дәүләт символларын булдырды. Боларны да озак вакыт танымаска тырыштылар. Һәм менә 2005 елның гыйнвар азагында, кабул ителүләренә ун елдан артык вакыт узгач, Татарстан дәүләт символларын Россия Федерациясе Дәүләт геральдика реестрына кертү турында карар кабул ителде, һәм шул хактагы таныклыклар Татарстан Президентына тапшырылды. Әлеге таныклыкларны тапшырганда РФ Президенты каршындагы Геральдика советы рәисе Георгий Вилинбахов: "Геральдика символикасына карата мөнәсәбәт үзебез яши торган җиргә мөнәсәбәт кебек булырга, бу - безнең ил, безнең герб, безнең флаг, дип кабул ителергә тиеш. Бөтен җәмгыятебез шуның белән сугарылган тәкъдирдә без, милли идеябез бар, дип әйтә алабыз", - диде.

Татарстанның беренче президенты Минтимер Шәймиев исә дәүләт символларының Татарстанда яшәүче күпмилләтле халык тарафыннан танылып, аны берләштерүен, хөрмәт һәм патриотлык хисләр уятуын басым ясап әйтте, Россия Федерациясе дәүләт символлары да шундый ук хисләр уятырга тиеш, дип искәртте.

СССР дигән ватанга афәт килгәч, илнең башка халыклары белән бергә, татарлар да уртак ватанны илбасарлардан саклап калу өчен изге көрәшкә күтәрелде, үз-үзләрен аямыйча көрәшеп, күп корбаннар биреп, татар халкы каһарманлыгының яңа сәхифәләрен язды. Шул халыкның бу илне үз ватаны дип атарга хакы юкмы?

Бүген, кайбер "кайнар башлар": 1941-1945 еллардагы сугышта безнең ата-бабаларыбыз чит дәүләтне саклап корбан булдылар", - дип акыл сатканда, укытучы-тәрбиячеләр балаларга "ватан", "патриотизм" төшенчәләрен тирәнрәк аңлатырга тиешләр. Дәресләрдә генә түгел, класстан тыш чараларда, һәртөрле очрашу-кичәләрдә балаларыбызга ватан өчен горурлык, патриотизм хисләре тәрбияләргә, илне-җирне саклап һәлак булганнарны олылап искә алырга, дәүләт символларын хөрмәтләргә өйрәтергә кирәк безгә. Югыйсә, бүген балаларыбыз "бэтманнар"ны, "пакимоннар"ны, һәртөрле монстрларның исемнәрен яхшырак беләләр. Ә геройларыбыз, халык бәхете өчен көрәшкән каһарманнар һаман онытыла бара. Күпләр Россия һәм Татарстан дәүләт символларының мәгънәсен дә юньләп белми.

Күптән түгел Калининград өлкәсенең бер районында укучыларның дәүләт символларын ни дәрәҗәдә белүен тикшереп караганнар. Нәтиҗәләр аяныч була: укучылар дәүләт символларын да, гимн авторларын да белми. Укучыларга патриотизм, ватанга мәхәббәт тәрбияләү максатында, хәзер өлкә мәктәпләрендә "Отечествоведение" дигән дәрес кертелә башлаган.

Ә менә АКШ мәктәпләрендә укучылар - инглизләр, японнар, кытайлар, Көньяк Америка илләреннән күчеп килгән эмигрант балалары, ак, кара тәнлеләр, метистлар һәм мулатлар - һәр көнне кулларын йөрәк өстенә куеп, Америка флагына тугрылыкка ант итәләр. АКШта булып, моны үз күзләре белән күреп кайткан Казан укучысы Алинә Гыйльметдинова бу хакта менә ничек яза:

"Ещё одна важная и заметная черта американской нации - патриотизм. Пусть иногда он кажется показным, но не может не впечатлять, когда каждый день, чтобы не случилось, американские школьники, кладя руку на сердце, клянутся в верности американскому флагу. Я чувствовала, что делают они это абсолютно искренне. И пусть американцы мало что знают об остальном мире, пусть у них слабое образование и наигранная приветливость, но они действительно любят свою страну и действительно гордятся ею. Очень хочется, чтобы и у нас было так же". ("Восточный экспресс", №9/3. 20-26 января 2005 года.) Моны бит укучы бала яза.

СССР таркалып, яшьләр белән шөгыльләнүче калмагач, илдә һәртөрле ультрауң фиркаләр, фашистлар идеологиясе белән коралланган яшьләр оешмалары барлыкка килде. Алар "ватан", "патриотизм" төшенчәләренә бөтенләй башка мәгънә сала, аны мәкерле максатларда файдаланырга омтыла. Соңгы вакытта Санкт-Петербургта, Воронежда һәм башка шәһәрләрдә шундый вакыйгалар булды һәм алар кабатланып тора, чөнки йөгәнсезләр җинаять җаваплылыгына тартылмый.

Бу уңайдан, ел башында Бөекбританиядә булган бер вакыйганы искә төшереп үтәсе килә. Королева Елизавета II оныгы - принц Гарри - бер дусты оештырган күңел ачу кичәсенә фашист офицеры формасы киеп бара. Яшь принцның бу гамәле ил күләмендә шау-шу тудыра. Кайбер сәясәтчеләр принцны хәтта хәрби уку йортына укырга алмаска, дигән таләп тә куялар. Принцка бу "шаяруы" өчен рәсми рәвештә гафу үтенергә туры килә.

Принцның әтисе исә, малаен акылга утырту өчен, аны дуңгыз фермасына эшкә җибәрә, иң шакшы эшләрне башкаруны йөкли.

Шул вакыйгадан соң, Европа илләрендәге ветераннар Европа берлегенең (Евросоюз) барлык илләрендә свастиканы (фашизм эмблемасын) куллануны бөтенләй тыю инициативасы белән чыга. АКШта автомобиль юлларында нацистлар яши торган төбәкләргә бару юнәлешен күрсәткән такталар алып ташлана.

Ә XX гасырның иң зур афәтен - фашизмны тар-мар иткән, миллионнарча корбаннар бәрабәренә бөтен Европага азатлык китергән илнең башкаласы - Мәскәү урамнарында свастикалы үсмерләр рәхәтләнеп йөри. Алай гына да түгел, һәртөрле башбаштаклык эшли, тыючы да, чара күрүче дә юк. Һәм болар барысы да соңгы елларда патриотик тәрбия эшенә тиешле игътибар булмаудан килә. Бу хакта 2005 елда Владимир Путин да Польшада немец фашистларының Освенцим концлагереннан тоткыннарны азат итүгә 60 ел тулуга багышланган чыгышында ачынып сөйләде, фашизмга каршы көрәштә иң күп корбаннар биргән илдә шундый күренешләр булуы өчен оят, диде. Әнә шуңа күрә дә бүген безгә патриотик тәрбиягә йөз белән борылырга һәм, балалар бакчасыннан башлап, югары уку йортларына кадәр, бу эш белән эзлекле шөгыльләнергә кирәк. Шул чагында яшь буында Ватан өчен горурлык хисләре дә тәрбияләнер, аларның туган илгә, туган җиргә хөрмәте дә артыр.

***Габделхак ШӘМСЕТДИНОВ,***
***тарих фәннәре кандидаты,***
***ТРның атказанган***
***мәдәният хезмәткәре***

# КОРЪӘН САВЫТЛАРЫ

2012 ЕЛ – ТАТАРСТАНДА КОРЪӘН ЕЛЫ

**Коръән - мөселманнарның изге китабы, шуңа күрә аны кадерләп, күз карасы кебек сакларга кирәк. Коръән китабы җирдән иң кимендә 70 сантиметр биеклеккә куелырга, чиста тукымага өч кат төрелгән булырга тиеш. Ул башка китаплар янына куелса да, аның иң өстә торуы зарур; бу изге китапка тәһарәтсез кагылырга һич тә ярамый. Шуның өчен дә Коръән китабы махсус савытларда саклана.**

ТР Милли музеенда Коръән савытларының геометрик формадагылары күбрәк, алар өчпочмак, турыпочмаклык рәвешендә гарәп хәрефләре белән бик матур язылып, үсемлек орнаментлары белән бизәлгән. Гадәттә, мондый савытларны ир-егетләр хатын-кызларга бүләк иткән.

Билгеле булганча, ТР Музеена 1895 елда нигез салына. Музей тарихы А.Ф.Лихачёв коллекциясе һәм 1890-1891 елларда Казанда үткәрелгән фәнни-сәнәгать күргәзмәсе материаллары нигезендә оешкан Казан шәһәре фән-сәнәгать музеена барып тоташа.

Андрей Федорович Лихачёв коллекциясе аеруча игътибарга лаек. Андагы 39920 предметның алты йөз егерме сигезе - татар халкының милли бизәнү әйберләре.

Бу тупланмада унбер Коръән савыты да бар. Алар алтын һәм көмештән эшләнгән. Көмеш алтын кебек үк затлы металл, әмма алтыннан ныграк. Осталар бизәнү әйберләре ясаганда аларның икесен бергә файдаланган, чөнки алар бер-берсен тулыландырган. Алтын йөгертелгән көмеш - бизәнү әйберен затлырак һәм күркәмрәк иткән. Кояш нурлары төсендәге алтын һәм зәңгәрсу көмеш - зәркәннәр өчен иң кулай чимал булып торган.

Идел буе татарлары зәркән сәнгатендә, нигездә, затлы металлдан җепкыр (ишкән, бөтерелгән алтын һәм көмеш җепләрдән зиннәтле бизәнү әйберләре ясау), каралту, кыру, уемлау ысуллары киң файдаланылган. Зәркәннәр әйберне затлы итү өчен кыйммәтле металлардан нәни бөртекләрне дә кулланган. Бу бөртекләр тиешенчә эшкәртелгәннән соң алдан әзерләнгән махсус ояларга беркетелгән.

Коллекциядә асылташлар белән бизәлгән Коръән савытлары да бар. Түгәрәк рәвешендә үзәге фирәзә асылташ белән бизәлгән Коръән савыты әнә шундыйлардан. Йөрәк рәвешендә эшләнгән савытлар да очрый.

ТР Милли музее залларында коллекциядәге Коръән савытлары белән "Казан татарларының бизәнү әйберләре" алтын хәзинәсендә танышырга, сокланырга мөмкин.

***Азат АХУНОВ әзерләде***
***Фотолар ТР Милли музееның рәсми сайтыннан (www.tatar.museum.ru) алынды***



# Оливер Стоунның улы ислам динен кабул иткән

**Танылган Голливуд кинорежисёры, продюсер һәм сценарийлар төзүче Уильям Оливер Стоунның улы Шон ислам динен кабул иткән. Үзенең карары турында яшь Стоун Иранда документаль фильм төшергән чакта белдерде, дип хәбәр итә "Франс Пресс" агентлыгы.**

Шулай итеп, Шон, христиан һәм яһүд диннәренә каршы килүче берни дә эшләмәгәнлеген, ә бары тик башка бик күп пәйгамбәрләрне кабул иткән кебек үк, Мөхәммәдне (сгв) дә кабул итүен белдерә.

2011 елның сентябрендә Торонтодагы кинофестиваль вакытында Шон Тәһранның атом-төш кораллары программасын һәм Иран җитәкчелеге сәясәтен яклап чыкты: "Аларга (иранлыларга) үз илләре белән ничек идарә итәргә кирәклеген күрсәтергә без кемнәр соң?"

Шунысын да билгеләп узарга кирәк: режиссёрның әтисе Оливер Стоун - тумышы буенча яһүд кешесе - үзенең Израильгә каршы карашлары белән билгеле. Ярты ел элек ул "Times" газетасына биргән әңгәмәсендә, европалы яһүдләрнең катастрофасы Америка яһүдләре аркасында килеп чыккан, дип белдергән иде.

2003 елда Оливер гарәпләр белән израильлеләр конфликты турында "Persona non grata" дип аталган бик тә эчтәлекле документаль фильм төшергән иде (биредә ул үзенең Йасир Гарәфәткә булган симпатиясен белдерә).

Узган көздә Иран президенты Мәхмүд Әхмәдинәҗад Оливер Стоунга илгә керергә һәм аның турында фильм төшерергә рөхсәт итте. Аңа кадәр режиссура өчен ике "Оскар"га ия булучы АКШ өчен уңай булмаган лидерлар - Уго Чавес һәм Фидель Кастро турында фильмнар төшергән иде.

Ислам динен кабул итеп, яшь Стоун үзенә Гали дигән исем алды.




# "Кайсыгызның кулы җылы?" хәйрия акциясе

*Аллаһы Сүбханәһү вә Тәгаләгә мактауларыбыз булса иде!*

"Ий, иман китергән бәндәләрем! Без сезгә биргән ризыкларны Ахирәт көне килеп җиткәнче үк (Хак юлында) сарыф итегез (сәдака бирегез, ятимнәргә булышыгыз, зәкят бирегез, хаж гыйбадәте кылыгыз). Ул Көн килеп җиткәч кенә алышбиреш тә, әшнәлек тә, шәфәгать тә булмаячак. Кяферләр золым итүчеләрнең үзедер" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 254 нче аять).

ТР мөселманнары Диния нәзарәте каршында эшләп килүче "Зәкят" хәйрия фонды мохтаҗларга, аз керемле, күп балалы гаиләләргә, инвалидларга, ятимнәргә, ялгыз картларга һәм авыру кешеләргә ярдәм итү йөзеннән, Мәүлид аена багышлап хәйрия акциясе уздыра.

Әлеге хәйрия акциясендә катнашып, көчегездән килгәнчә ярдәм итүегезне сорыйбыз.

Благотворительный Фонд Закят

Акция барышында азык-төлек җыелмалары тарату, мохтаҗларга акчалата ярдәм күрсәтү каралган.

"Сез ярдәм иткән мескен кеше сезне оҗмахка җитәкләп алып керер!"

Акчалата ярдәм күрсәтергә теләүчеләр өчен "Зәкят" хәйрия фондының реквизитлары:

Расчетные счета:
ИНН/КПП 1655068682 / 165501001
ОГРН 1091600003153 ОКПО 63107012
Р/с: 40703810400020000071
в ОАО "Ак Барс банк" г.Казань, ул.Декабристов, д.1
К/с: 30101810000000000805
БИК: 049205805
Назначение платежа: благотворительность (указать обязательно!)

**Адрес: 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт.**
**Тел: +7 (843) 236-46-32, 264-60-08.**
**Электрон почта: fondzakyat@yandex.ru.**
**Фондның сайты: www.закят.рф.**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 18.02.12 | 6:33 | 8:03 | 13:02 | 16:16 | 17:53 | 19:23 |
| *Якшәмбе* | 19.02.12 | 6:31 | 8:01 | 13:02 | 16:17 | 17:55 | 19:25 |
| *Дүшәмбе* | 20.02.12 | 6:28 | 7:58 | 13:02 | 16:19 | 17:57 | 19:27 |
| *Сишәмбе* | 21.02.12 | 6:26 | 7:56 | 13:02 | 16:20 | 17:59 | 19:29 |
| *Чәршәмбе* | 22.02.12 | 6:24 | 7:54 | 13:02 | 16:22 | 18:02 | 19:32 |
| *Пәнҗешәмбе* | 23.02.12 | 6:21 | 7:51 | 13:02 | 16:23 | 18:04 | 19:34 |
| *Җомга* | 24.02.12 | 6:19 | 7:49 | 13:02 | 16:25 | 18:06 | 19:36 |
| *Шимбә* | 25.02.12 | 6:17 | 7:47 | 13:02 | 16:26 | 18:08 | 19:38 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №7 (124) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-527.

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 16 февраль көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).